ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ ____________ КАРАР

с. Верхний Услон

476

Татарстан Республикасының
Югары Ослан муниципаль районы
ихтыяҗлары өчен товарлар китерү,
эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү
предметы булган контрактларны банк
белән тәэмин итү очракларын
билгеләү турында.

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында»2013 елның 05 апрелендәге 44 номерлы Федераль законның 35 статьясындагы 2 өлеше нигезендә, "Контрактларны банк белән тәэмин итү турында" Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 20 сентябрендәге 963 номерлы карары беләнТатарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар китерү, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү предметы булган контрактларны банк белән тәэмин итү очракларын расларга. (1 нче кушымта)
2. Әлеге карар үз көченә кергәнче төзелгән контрактларга карата әлеге карар белән расланган контрактларны банк белән озата баруны гамәлгә ашыру очраклары кулланылмый дип билгеләргә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының http://verhniy-uslon.tatarstan.ru/ рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе Л.С. Хакимзянов

Әзерләде һәм бастырып чыгарды
Арсланова Р.Р.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль
районы башкарма комитеты
Җитәкчесенең
2017 _________
______карары белән
Расланган
1 кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар китерү, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү контрактларын банк белән тәэмин итү очраклары

Югары Ослан муниципаль районы башкарма комитеты - Югары Ослан муниципаль районы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар башкарганда вәкаләтле орган «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» Федераль законның 34 статьясындагы 26 өлеше нигезендә контрактка кертергә хокуклы, әгәр мондый контрактның башлангыч (максималь) бәясе (бердәнбер тәэмин итүче (подрядчы, башкаручы) белән контракт бәясе) түбәндәгечә булса:

- 200 млн. сумнан да ким түгел - контракт үтәүдә банк тарафыннан тәэмин итүче яисә заказчы тарафыннан җәлеп ителгән контрактны уздыруда төзелә торган шарт;

- ким дигәндә 5 млрд. сум - тәэмин итүче яки банкның заказчысы тарафыннан киңәйтелгән банк озатуы кысаларында җәлеп итүне күздә тоткан шарт.

Әлеге очраклар Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы ихтыяҗлары өчен товарлар китерү, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү предметы булган контрактларны банк белән тәэмин итүне гамәлгә ашыру Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 20 сентябрендәге 963 номерлы карары нигезендә эшләнгән.

Башкарма комитет эшләре белән идарә итүче А.К. Минһаҗева